РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Буа шәһәре **КАРАР**

06.03.2025 №69/Бк/к

«Буа муниципаль районы территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында» 2008 елның 16 апрелендәге 83 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә Буа муниципаль районы территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәү максатларында Буа муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Буа муниципаль районы территориясендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында» 2008 елның 16 апрелендәге 83 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә :

1.1. 2 пунктның а пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

8. Кар капламы эрегән көннән алып көзге яңгырлы тотрыклы һава торышы урнашканчыга кадәр яисә кар капламы барлыкка килгәнчегә кадәр урманнарда тыела:

а) ылыслы яшь агачлыкта, зыян күргән урман участокларында, торф сазлыкларында, кисү урыннарында (урманда), кисү калдыкларыннан (агачларны аударганда һәм ботакларын тураганда, шулай ук кәүсәләрне ботаклардан чистартканда барлыкка килгән агач калдыклары, киселгән агачларның өске өлешләрен, киселгән агачларны, ботакларны, чыбыкларны үз эченә ала) һәм әзерләнгән агачтан чистартылмаган агач кисү урыннарында (урман кисүендә), кипкән үләнле урыннарда, шулай ук агач ябалдашлары астында ачык ут (учак, эретеп ябыштыру лампалары, примуслар, мангаллар, мичләр) куллану. Башка урыннарда ачык уттан файдалану киңлеге 0,5 метрдан да ким булмаган янгынга каршы минераллаштырылган (ягъни туфракның минераль катламына кадәр чистартылган) полоса белән аерылган мәйданчыкларда рөхсәт ителә. Ачык ут (учак, мангал, кыздыру урыны) кисү калдыкларын яндырып бетергәннән яки аны башка максат белән файдаланганнан соң яхшылап җир белән күмелә яки тулысынча яну беткәнче су сибелә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми рәвештә бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/, һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Буа муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) интернет челтәрендә һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов